ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.М.Джалиля, д.23/33, г. Мамадыш,
Республика Татарстан, 422190

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
М.Җәлил ур, 23/33 й., Мамадыш ш.,
Татарстан Республикасы, 422190

Тел.: (85563) 3-15-00, 3-31-00, факс 3-22-21, e-mail: mamadysh.ikrayona@tatar.ru, www.mamadysh.tatarstan.ru

**Постановление** **Карар**

№ 404 от «02» 11 2024 г.

Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль районы
Башкарма комитетының аерым
карарларының үз көчләрен
югалтуын тану турында

Муниципаль хокукый актлар системасын актуальләштерү максатларында, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетының 2024 елның 02 сентябрендәге Мамадыш муниципаль районының «Шәһәр хуҗалыгы» муниципаль унитар предприятиесен хосусыйлаштыру турында» 2024 елның 02 сентябрендәге 321 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетының түбәндәге карарларын үз көчен югалтты дип танырга:

- 2024 елның 11 апрелендәге «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетының 2024 елның 27 февралендәге 79 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында» 142 нче номерлы ;
- 2024 елның 27 февралендәге «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы «Шәһәр хуҗалыгы» муниципаль унитар предприятиесе тарафыннан күрсәтелә торган «НОКРАТ» пляж комплексы хезмәтләренә һәм мунча хезмәтләренә тарифлар билгеләү турында» 79 нчы номерлы;
- 2022 елның 18 маендагы 18.05.2022 «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының «Шәһәр хуҗалыгы» муниципаль унитар предприятиесе күрсәтә торган балалар аттракционнары хезмәтләренә һәм спорт инвентарен прокатка чыгаруга тарифлар билгеләү турында» 141нче номерлы.

2. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетының матбугат һәм массакүләм чаралары белән хезмәттәшлек секторына әлеге карарны интернет мәгълүмати - коммуникацион челтәрендәге Татарстан Республикасының хокукый рәсми порталында һәм Мамадыш муниципаль районының www.mamadysh.tatarstan.ru рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче Р.М.Гарипов

0000012429